# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«29» 08 2022 ел Яр Чаллы № 2428

Җирләрне Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү һәм аларда махсус сакланылучы территорияләр булдыру турында

РФ Җир кодексы, «Җирләрне җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү, аларны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә файдалану һәм саклау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2020 елның 21 октябрендәге 2/11 номерлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. 16:39:102101:327 кадастр номерлы, 38204 кв. м мәйданлы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Кече Шилнә авыл җирлеге, Пионер лагерьлары территориясе, җир кишәрлеге 6/327; җирләрнең категориясе: сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр булган җир кишәрлеген, гражданнарның ялын, туризмын, физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшчәнлеген оештыру өчен, Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертергә.
2. 16:39:102101:327 кадастр номерлы җир кишәрлеге чикләре белән туры килүче чикләрдә махсус сакланылучы территориянең чикләрен расларга.
3. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланыла торган территорияне кушымта нигезендә төзергә.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның «29» 08
2427 номерлы карарына кушымта

